**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге составына керүче Шилнәбаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

13 октябрь, 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 12 нчы, 13 нче, ноябрендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2023 елда яшәү урыны буенча Шилнәбаш авыл җирлеге Шилнәбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз илле) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү («Безнең ишегалды» программасында катнашу өчен сарайларны сүтү һәм утильләштерү), махсус техника хезмәтләре;
- вак таш белән юллар сатып алу һәм салу, юлларга чокырларны ямау;
- Шилнәбаш авылындагы суэтем башняларын сатып алу һәм урнаштыру;»

;

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 944 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 538 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 532 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 6 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Шилнәбаш авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2023 елда яшәү урыны буенча Шилнәбаш авыл җирлеге Шилнәбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз илле) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм

көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү («Безнең ишегалды» программасында катнашу өчен сарайларны сүтү һәм утильләштерү), махсус техника хезмәтләре;

- вак таш белән юллар сатып алу һәм салу, юлларга чокырларны ямау;

- Шилнәбаш авылындагы суэтем башняларын сатып алу һәм урнаштыру;»

3. Шилнәбаш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә.

4. Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Шилнәбаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

5. Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Шилнәбаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шилнәбаш авыл җирлеге Башлыгы О.А. Гончарова